КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 август г.Казань № 967

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 256 нчы; 2010 ел, 9 март, 124 нче; 2017 ел, 24 ноябрь, 900 нче; 2022 ел, 27 июнь, 606 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктта «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәдә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның уникенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.3.1 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә пестицидлар һәм агрохимикатлар белән эш итүне тәртипкә салу турында» 2007 ел, 17 сентябрь, 467 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасында Үсемлекләрне саклау буенча федераль дәүләт территориаль станциясе» федераль дәүләт учреждениесе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, башка кызыксынучы министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, башка кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Татарстан Республикасында Үсемлекләрне саклау буенча федераль дәүләт территориаль станциясе» федераль дәүләт учреждениесенә» сүзләрен «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 22 май, 347 нче; 2015 ел, 14 август, 589 нчы; 2016 ел, 23 июнь, 434 нче; 2021 ел, 21 апрель, 266 нчы; 2022 ел, 27 апрель, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, су асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта татар текстында «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органнарының» сүзләрен «тиешле федераль башкарма хакимият органнарының һәм республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләрен «федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләрен «федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 апрель, 354 нче; 2021 ел, 21 гыйнвар, 18 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1097 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

исемендә «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын раслау турында» 2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «дәүләт хакимиятенең җавап бирүче башкарма органы» сүзләрен «җавап бирүче республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

6. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында санитария-экология хәлен яхшырту чаралары турында» 2005 ел, 5 сентябрь, 429 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының экологик иминлек концепциясен раслау турында (2007 – 2015 елларга)» 2007 ел, 3 сентябрь, 438 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең су стратегиясен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чаралары планын раслау турында» 2011 ел, 4 август, 637 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы карарындагы 6 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин